КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 816

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү аркасында гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә Африка дуңгызлар чумасы чыганакларын барлыкка килүне һәм юкка чыгаруны булдырмау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дуңгызларны һәм (яисә) дуңгызчылык продуктларын алырга:

Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Килди авыл җирлеге, Килди авылы адресы буенча, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Килди авылы, Уланово авылы, Федяево авылы, Харино авылы, Коргуза авылы территорияләрендә урнашкан «Пашков Сергей Игоревич» крестьян (фермер) хуҗалыгы территориясендә;

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Борак авыл җирлеге, Коминтерн п., Садовая ур., 20 йорт адресы буенча урнашкан шәхси ярдәмче хуҗалык территориясендә: , шулай ук Спас муниципаль районының Красная Слобода авылы, Щербеть авылы, Бугровка авылы, Борак авылы, Кожаевка авылы, Коминтерн п.,

Вожи авылы,  Измери авылы территорияләрендә урнашкан шәхси ярдәмче хуҗалык территориясендә.

2. Карарга терәклгән Хайваннарны  һәм терлекчелек продуктларын алуны гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне гамәлгә ашыру буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 пунктында каралган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                     А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 13 август, 816 нчы
карары белән расланды

Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гатин Идрис Мөдәрис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Зиатдинов Марат Галимҗан улы | «Югары Ослан район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Камалов Ильяс Локман улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Алексеевск территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Осокин Валерий Александровичны | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сафин Фиргать Мәсгуть улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Апас территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Шакиров Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шәкүров Булат Әбрар улын | «Спас район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы. |

___